**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕТУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 57-3-12, факс 57-3-12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15 .10. 2022** **№ 4**

**2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Олы Тормы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 08 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Чулла авылы, Иванов урамы, 10 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 08 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару турында килешәсезме:

- Чулла торак пунктында җир күперен ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?».

"КАРШЫ" "РИЗА"

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/).

5. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Н.Г. Салихов**